ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.05.2024 г. Заинск № 271

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 октябрендәге 2271 номерлы "Зәй муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында" карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы "Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эш итү тәртибен раслау турында" карарына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 октябрендәге 2271 номерлы "Зәй муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында"гы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

И.В.Гөбәйдулина
(85558)3 37 47